Әссәламv галәйкvм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтvһ, газиз ватандашларым, хөрмәтле дин кардәшләрем! Форсаттан кулланып Мордовия Республикасында Россия Федерациясе моселманнарынын Үзәк диния нәзарәты вәкилияте тарафыннан, шәхсән vземнен әтрафымнан барчагызны да киләсе мобарәк Гарәфә коне һәм Ид-әл-Әдха Курбан гаете бәйрәме унаеннан чын ихлас кvнелемнән тәбрик итәм!

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә Кәvсәр сvрәсендә болай дия: «Шәфкатьле, рәхимле Аллаһ исеме белән...
Без сина, хакыйкатьтә, Кәvсәр бирдек.
Һәм Раббына намаз vтә һәм корбан чал!
Хакыйкатьтә, сине кvрәлмаучы – отек булучыдыр». Аллаһы Раббыбыз пәйгамбәребез Мохәммәд галәйһиссәләмгә боера: «Намаз vтә - фарыз гамәл һәм корбан чал!», Раббыбызнын Коръәни Кәримендә һәрбер аятендә һәм һәрбер сvзендә мәгънә һәм хикмәт бар, шул сәбәпле мәзхәб башлыгыбыз Имам Әгъзам абу Хәнифә Ногман ибн Сәбит әл-Куфи хәзрәтләре vзенен ижтиһадында бу турыда болай дигән - зәкәт тvләv нисабы булган бәндәләр очен корбан гамәле кылу вәжиб рәтенә керә, әгәр дә шушы гамәл vтәлми калса бәндә Аллаһы Тәгалә хозурына гонаһлы булып калыр, - дип ижтиһад кылган.
Хормәтле дин кардәшләрем, шушы золхижжә аенын мобарәк коннәрендә Аллаһ разыйлыгын омет итеп шокрәнә рәвешендә суелган корбаннарыгызны Ходай Тәгалә кабул әйләсен! Корбаннарыгызны Аллаһы Собханәһу вә Тәгалә хозурына ниятләп юллаган вакытта ботен изге хәер-догаларыгызны, хыялларыгызны һәм теләкләрегезне Хак Тәгалә тормышка ашырсын, чонки бернәрсә дә бәндәнен тәгъдирен алмаштыра алалмыйм мәгәре догадан һәм гамәлдән гайре.
Хажжиләребезнен Мәккә Мокәр-рәмә дә һәм Мәдинә Монәввәрә дә кылган изге йола-гамәлләрен Аллаһы Тәгалә кабул әйләсен!
Даими рәвештә шушы тәшрик коннәрне Ватаныбыз, кvп милләтле халкыбыз, хәрбиләребез, дәvләт житәкчеләребез һәм тvрәләребез очен хәер-догада бергә булык бердәм булык!
Барчагызга да зур ихтирам, хәер-дога, кайнар сәламләр белән,

**Рафаэль-хәзрәт МАНЮРОВ,**
*Мордовия Республикасында Россия Федерациясе мөселманнарынынҮзэк диния нэзарэты тулы хокуклы вэкиле*